## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**13 ноябрь, 2020 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 6 ноябрендә 16 сәгать 30 минутта, 8 ноябрендә 16 сәгатьтә, 10 ноябрендә 16 сәгатьтә, 12 ноябрендә 11 сәгатьтә, 16 сәгатьтә 30 минут, 13 ноябрендә 11 сәгатьтә булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- материаллар сатып алып, урам утларын агымдагы ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

- Олы Подберезье торак пунктында да кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;

- Олы Подберезье торак пунктында җәйге чорда үләнне чабу;

- Полевая урамындагы 8 нче номерлы йорттан 18 нче номерлы йортка кадәр, Карл Маркс урамындагы 21 нче номерлы йортка кадәр, Калинин урамында 34 нче номерлы йортка кадәр юл челтәренщ вак таш җәю һәм нигез салу;

- Олы Подберезье т. п. зиратларны чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- су башнясын лицензияләү буенча түләү (су белән тәэмин итү чыганагының артезиан скважинасын куллану, суны анализлау һәм башка документларны документаль рәсмиләштерү).

Экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 476 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 285, бу 59 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен гражданнар җыенында 280 катнашучы тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенның 5 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкару өчен юлларга:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- материаллар сатып алып, урам утларына агымдагы ремонт (килешү буенча эшләр өчен түләү);

б) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

- Олы Подберезье торак пунктында да кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;

- Олы Подберезье торак пунктында җәйге чорда үләнне чабу;

- Полевая урамындагы 8 нче номерлы йорттан 18 нче номерлы йортка кадәр, Карл Маркс урамындагы 21 нче номерлы йортка кадәр, Калинин урамында 34 нче номерлы йортка кадәр юл челтәренщ вак таш җәю һәм нигез салу;

в) җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:

- Олы Подберезье т. п. зиратларны чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

г) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- су башнясын лицензияләү буенча түләү (су белән тәэмин итү чыганагының артезиан скважинасын куллану, суны анализлау һәм башка документларны документаль рәсмиләштерү).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен юлларга.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Олы Подберезье авыл җирлеге Башлыгы О.М.Емельянова